КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 июнь г.Казань № 709

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 май, 356 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 408 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2018 ел, 14 март, 152 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1153 нче; 2020 ел, 22 июль, 617 нче; 2022 ел, 23 июнь, 602 нче; 2023 ел, 26 гыйнвар, 49 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2022 елның 29 апрелендәге 24-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 5 статьясы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2022 елның 29 апрелендәге 24-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 5 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның икенче абзацында «тәкъдимнамәләрне» сүзен «күрсәтмәләрне» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе Президенты актларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Рәисе указларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын үтәү йөзеннән норматив хокукый актларны үз вакытында чыгаруны һәм аларны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрүне тәэмин итәргә;»;

әлеге карар белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләренең 1.7 пунктында «тәкъдимнамәләрне» сүзен «күрсәтмәләрне» сүзенә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының юридик хезмәте турындагы бертип нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 12 декабрь, 639 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2017 ел, 1 август, 534 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика башкарма хакимият органының юридик хезмәте турындагы бертип нигезләмәне раслау хакында»;

преамбулада «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының юридик хезмәте турында бертип нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика башкарма хакимият органының юридик хезмәте турында бертип нигезләмә»;

1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Юридик хезмәтнең төп бурычлары – республика башкарма хакимияте органы эшчәнлеген хокукый яктан тәэмин итү, республика башкарма хакимият органы компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнарын камилләштерүгә бәйле эшне башкару, шулай ук норматив хокукый актлар проектларының сыйфатын яхшырту.»;

3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органына» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«республика башкарма хакимият органы компетенциясе өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү буенча һәм республика башкарма хакимият органы вәкаләтләрен төгәлләштерү буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнаша;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөстәкыйль яисә республика башкарма хакимият органының башка структур бүлекчәләре белән берлектә республика башкарма хакимият органы компетенциясе өлкәсендәге законнар мониторингын гамәлгә ашыра;»;

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

уналтынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырырга;

унҗиденче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«республика башкарма хакимият органы, аның территориаль органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалары хезмәткәрләренә республика башкарма хакимият органы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча хокукый ярдәм күрсәтә;»;

унтугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

егерменче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Республика башкарма хакимият органы эшендә законнарның бозылуын ачыклаган юридик хезмәт җитәкчесе (башлыгы) бу хакта республика башкарма хакимият органы җитәкчесенә хәбәр итәргә тиеш.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы; 2018 ел, 12 май, 350 нче; 2018 ел, 18 май, 375 нче; 2018 ел, 24 июль, 592 нче; 2018 ел, 8 сентябрь, 762 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1127 нче; 2019 ел, 19 апрель, 311 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1192 нче; 2020 ел, 11 февраль, 94 нче; 2020 ел, 17 март, 196 нчы; 2020 ел, 27 май, 429 нчы; 2020 ел, 28 июль, 629 нчы; 2020 ел, 2 октябрь, 902 нче; 2020 ел, 6 ноябрь, 1000 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1259 нчы; 2021 ел, 3 февраль, 48 нче; 2021 ел, 16 июнь, 465 нче; 2021 ел, 29 декабрь, 1311 нче; 2022 ел, 17 сентябрь, 1014 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1460 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2.2.2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан

Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.7 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.8 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.15 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты актларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе актларын» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.27[1] пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.50 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген камилләштерү чаралары турында» 2006 ел, 31 август, 441 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 31 гыйнвар, 52 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 734 нче; 2018 ел, 19 апрель, 264 нче; 2018 ел, 21 ноябрь, 1034 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика башкарма хакимият органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген камилләштерү чаралары турында»;

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «министрлыкларның һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә

алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «Министрлыкларга һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кайбер норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 24 декабрь, 883 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 1 июнь, 461 нче; 2018 ел, 1 октябрь, 891 нче; 2019 ел, 11 февраль, 91 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Кайбер норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

$15^2$ пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Татарстан

Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында» 2016 ел, 28 июнь, 447 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 14 апрель, 227 нче; 2022 ел, 25 февраль, 161 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында»;

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналының редакция коллегиясе составында Л.Ю.Глухованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалану тәртибе турында» 2016 ел, 22 август, 581 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 1 апрель, 257 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 775 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәт бирү тәртибе хакындагы нигезләмәдә:

2 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле тармак органы» сүзләрен «тиешле тармак республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

$3^1$ пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тармак органы» сүзләрен «тармак республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза

тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын тормышка ашыру чаралары хакында » 2017 ел, 15 август, 580 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына җәмәгатьчелек фикер алышуын тәэмин итү турындагы нигезләмәдә:

исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Казан шәһәренә нигез салуның 1000 еллыгын әзерләү һәм үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2001 ел, 20 гыйнвар 13 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең яңа составы эшчәнлеген оештыруны тәэмин итү чаралары турында» 2001 ел, 14 май, 275 нче;

«Бюджет һәм салым өлкәләрендәге Татарстан Республикасы законнары проектларына ачык бәйсез экспертизаны мәҗбүри үткәрү  турында» 2008 ел, 25 июнь, 445 нче;

«Татарстан Республикасында дини экстремистлыкны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш чаралары турында» 2012 ел, 31 август, 749 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин